**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай мунициҗипаль районы Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**11 ноябрь 2025 ел** **№2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай мунициҗипаль районы Тымытык авыл җирлеге Башлыгының "Татарстан Республикасы Азнакай мунициҗипаль районының Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында" 27.10.2025 ел № 3 карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай мунициҗипаль районының Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, 1 нче төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш үзара салым кертергә.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Җәлил, Совет, Тукай урамнары буйлап вак таш сатып алу, төяү, ташу, җәю).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62 нче йорт; Әгер авылы Совет ур., 27 нче йорт адреслары буенча Тымытык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Азнакай мунициҗипаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай мунициҗипаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Мостафина